АЛЕКСЕЕВСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
АЛЕКСЕЕВСК
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25.07.2019 № 255

п.г.т. Алексеевское

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районында**
**муниципаль хезмәт турындагы**
**Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Гамәлдәге законннарга, шул исәптән Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезләмәләренә, “Мәҗбүри пенсия иминияте системасында шәхси (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында”гы 1 апрель 2019 ел, 48-ФЗ санлы Федераль законга һәм Россия Федерациясенең кайбер закон чыгару актларына туры китерү максатында

**Алексеевск муниципаль районы Советы карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районыАлексеевск район Советының 14.09.2018 ел, 193 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагыНигезләмәгәтүбәндәге эчтәлектәге үзгәрешләрне кертергә:

27.9 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«27.9. Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турындагыКодексының 32 нче маддәсендә каралган җәзалар мунципаль хезмәткәр кылган хокук бозулар көненнән алып, хезмәткәрнең авыруына, аның отпуск ялында булуына, шулай ук хезмәткәрләрнең вәкаләтле органы фикерен исәпкә алу өчен кирәкле вакытка да карамастан,бер айдан да соңга калмыйча карала.Дисциплинар җәза, Россия Федерациясенең коррупциягә каршы көрәш турындагы законнарында билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, вазыйфаларныүтәмәгәнөчен коррупцион хокук бозуларны кылган көннән алып өч елдан соңрак кулланыла алмый.

16.3 пунктның 6 нчы пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“6) шәхси (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ, шул исәптән электрон документ формасында.

2. Әлеге карарны Алексеевск муниципальрайонының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында мәгълүмати-телекоммуникацион Интернет челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Совет рәисе урынбасары Г.В. Беловагайөкләргә.

**Муниципаль район башлыгы,**
**Советрәисе** **С.А. Демидов**